КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 5 декабрь г.Казань № 1557

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урынын төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларына кертү турында» 2009 ел, 16 июль, 497 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Свияжск утрау-шәһәре» истәлекле урынын төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларына кертү турында» 2009 ел, 16 июль, 497 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 9 декабрь, 1030 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «1 нче кушымтада күрсәтелгән чикләрдә һәм 2 нче кушымтада бирелгән картографик тасвирлама нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче һәм 2 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин